КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 24 март г.Казань № 347

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының резерв фонды акчасын тоту тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2002 ел, 14 февраль, 64 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының резерв фонды акчасын тоту тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының резерв фонды акчасын тоту тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2002 ел, 14 февраль, 64 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2002 ел, 28 июнь, 373 нче; 2006 ел, 30 декабрь, 693 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының резерв фонды акчасын тоту тәртибе турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә

1 пунктта «чираттагы финанс елына» сүзләрен төшереп калдырырга, «һәм план чорына» сүзләрен өстәргә;

3 пунктның унбишенче абзацында «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин